КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 сентябрь г.Казань № 1090

2024 – 2026 елларга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны;

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләмен.

2. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, «Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә, туклану өчен махсус сөт продуктларын һәм катнашмаларын алучы өч яшькә кадәрге балаларны аларның категорияләре, яшьләре һәм алына торган продукция төрләре буенча аерым исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 26 август, 913 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 ел, 26 август, 913 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 ел, 01 ноябрь, 1167 нче;

4. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 6 сентябрь, 1090 нчы
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан медицина оешмалары каршындагы сөт өләшү пунктлары һәм яхшы сыйфатлы туклану пунктлары аша өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар

| Балалар тукلануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар алучылар категориясе | Елы | Түбәндәге яшьтәге балаларга норматив чыгымнар, 1 көнгә сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 0 айдан 6 айга кадәр | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр |
| 1 | . | 3 | 4 | 5 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар тукلануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | 2024 | 28,23 | 59,02 | 41,02 |
| | 2025 | 29,36 | 61,38 | 42,66 |
| | 2026 | 30,53 | 63,83 | 44,37 |
| | 2024 | 112,92 | - | - |

| 1 | . | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 2025 | 117,44 | - | - |
| | 2026 | 122,12 | - | - |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 6 сентябрь, 1090 нчы
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар алучылар категориясе | Балаларның яше | Елы | Бер елга дәүләт эше күләме, бала көне | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | . | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 2024 | 663 558 | - | - | - |
| | | 2025 | 694 595 | - | - | - |
| | | 2026 | 698 975 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 яшькә кадәр | 2024 | 3 044 388 | 3 044 388 | 3 044 388 | 3 044 388 |
| | | 2025 | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 | 3 038 990 |
| | | 2026 | 3 037 895 | 3 037 895 | 3 037 895 | 3 037 895 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | 2024 | - | 11 180 202 | 11 180 202 | 11 180 202 |
| | | 2025 | - | 11 152 940 | 11 152 940 | 11 152 940 |
| | | 2026 | - | 11 154 035 | 11 154 035 | 11 154 035 |

| 1 | . | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| белән түләүсез тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | | | | | | |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 2024 | 19 398 | - | - | - |
| | | 2025 | 24 455 | - | - | - |
| | | 2026 | 23 360 | - | - | - |

_____________________________